**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ VIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 16**

Яңа Усы авылы «03» март 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 февралендәге 14 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Яңа Усы авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затлар милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны рациональ файдалану, саклау һәм яңадан җитештерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 февралендәге, 14 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3 пунктына 3.3.2.1 пунктчасын өстәргә: «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар (мөрәҗәгать итүчедә булмаган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына)»;

1.2. 1.2. 3.3.6 пунктны 3.3.6.1 пунктчасы белән тулыландырырга: «Мөрәҗәгать итүче 3.3.2.1 пунктчасында күрсәтелгән документларны

тапшырмаган очракта. җирле үзидарә органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып ала:

1) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.»;

2) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә хокуклар турында өземтә.».

1.3. 3.11.4 пунктына 3.11.4.1 пунктчасын өстәргә: «Рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның тулы күләмдә тапшырылмавы, я тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) төгәл булмаган мәгълүматның булуы;

- әгәр тиешле документ гариза бирүченең үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, ведомствоара мөрәҗәгатькә дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә яки дәүләт хакимияте органы һәм җирле үзидарә органы карамагында булган оешмадан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат булмауны дәлилләүче җавап килү;

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы** **Г.С.Романова**